МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.04.2018 Казан шәһәре № под-707/18

«Гомуми белем бирү фәннәре буенча мәктәп укучыларының Бөтенроссия олимпиадасы призерларын һәм җиңүчеләрен әзерләгән педагогик хезмәткәрләргә ярдәм» гранты турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 12 апрелендәге 238 номерлы «2018 елда Мәгариф өлкәсендә грантлар турында» карарын үтәү һәм Татарстан Республикасы территориясендә олимпиада хәрәкәтен үстерү максатларында б о е р а м:

1. «Гомуми белем бирү фәннәре буенча мәктәп укучыларының Бөтенроссия олимпиадасы призерларын һәм җиңүчеләрен әзерләгән педагогик хезмәткәрләргә ярдәм» грантын оештырырга.

2. «Гомуми белем бирү фәннәре буенча мәктәп укучыларының Бөтенроссия олимпиадасының йомгаклау этабы призерларын һәм җиңүчеләрен әзерләгән педагогик хезмәткәрләргә ярдәм» гранты турында положениене (алга таба - Грант) расларга.

3. Гомуми белем бирү идарәсенә (Т. Т. Федоровага ) 2018 елның 1 июненнән 15 июленә кадәр грант алу өчен конкурс сайлап алуны оештырырга һәм үткәрергә.

4. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Республика олимпиада үзәге» дәүләт автоном белем бирү учреждениесенә (Г.Д.Зариповага) грантны оештыру-методик яктан тәэмин итәргә.

5. Бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге (Г. К. Мөхәммәдкәримова) Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында каралган акчалар кысаларында грантны финанслауны тәэмин итәргә.

6. Гомуми белем бирү идарәсенә (Т. Т. Федоровага) өч көнлек срокта әлеге боерыкны Татарстан Республикасы юстиция министрлыгына тапшырырга.

7. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

8. Башкаруны контрольдә тотуны үземә калдырам .

Министр вазыйфаларын башкаручы И.Г. Хадиуллин

Расланган
Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы
18.04.2018 ел № под-707/18
боерыгы белән

«Гомуми белем бирү фәннәре буенча мәктәп укучыларының Бөтенроссия олимпиадасы призерларын һәм җиңүчеләрен әзерләгән педагогик хезмәткәрләргә ярдәм» гранты турында
положение

1. Гомуми положениеләр

1.1. Әлеге положение «Гомуми белем бирү фәннәре буенча мәктәп укучыларының Бөтенроссия олимпиадасы призерларын һәм җиңүчеләрен әзерләгән педагогик хезмәткәрләргә ярдәм» грантына (алга таба - грант) конкурс сайлап алуны оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели.

1.2. Грант Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән гамәлгә куела (алга таба - министрлык).

1.3. Грант сәләтле балаларны һәрьяклап үстерү һәм аларга ярдәм итү, укучыларны гомуми белем бирү фәннәре буенча Бөтенроссия олимпиадасында катнашуга әзерләү буенча педагогларда мотивация тудыруга ярдәм итәчәк.

1.4.Грантта катнашучылар Грантны гамәлгә куючы (грант бирүче), Грантка дәгъва кылучы һәм грант алучы тора .

Грантны гамәлгә куючы (грант бирүче) - грантлар бирү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы министрлык.

Дәгъва кылучы- положение нигезендә грант алуга конкурс узарга әзер, педагогик хезмәткәрләрне белем бирү оешмасына җәлеп итү өчен грантлар турындагы положениенең 2.6 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килә торган физик зат.

Грант алучы- төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын яки өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы, мәгариф оешмасында эшләүче һәм грант алуга конкурс узган, әлеге положениедә билгеләнгән таләпләргә туры килә торган физик зат.

1.5. Грант үз эченә ала:

Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларының төп гомуми белем бирү программаларын яки өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы 9-11 сыйныф укучылары арасында мәктәп укучыларының Бөтенроссия олимпиадасының йомгаклау этабы призерларын/җиңүчеләрен әзерләгән грант алучының хезмәт хакына айлык стимуллаштыра торган өстәмә түләүне.

1.6. Грант шәхси һәм өченче физик затларга тапшырыла алмый.

1.7. Грантларның саны ел саен Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларының 9-11 нче сыйныф укучылары арасында Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабы нәтиҗәләре буенча һәм әлеге положение нигезендә билгеләнә.

1.8. Конкурс йомгаклары буенча республика конкурс комиссиясе грант алучыларның хезмәт хакына ,Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларының 9-11 сыйныф укучылары арасында гомуми белем предметлары буенча Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабында призер(лар) / җиңүче(ләр) әзерләгән өчен түләнә торган, ай саен стимуллаштыра торган өстәмә түләүнең суммасын күрсәтеп, грант алучылар исемлеген төзи.

1.9. Грантның гамәлдә булу срогы календарь уку елының 1 сентябреннән киләсе календарь елның 31 августына кадәр

## 2. Конкурста катнашу өчен гаризалар бирү

2.1. Грантта катнашу өчен, югары белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләре, гомуми белем бирү оешмаларының һәм өстәмә белем бирү оешмаларының түбәндәге таләпләргә туры килә торган педагогик хезмәткәрләре дәгъва итә ала:

төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын яки өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруда катнашу;

Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларының 9-11 нче сыйныф укучылары арасында гомуми белем фәннәре буенча Бөтенроссия мәктәп укучылары

олимпиадасының йомгаклау этабы призерын(ларын)/ җиңүчене(ләрне) әзерләүнераслый торган документлар булу.

2.2. Грант бирүче гаризалар тапшыру башланырга ун календарь көннән дә соңга калмыйча, «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтта боерык урнаштыру юлы белән конкурс үткәрү турында игълан итә.

2.3. Грантка дәгъва кылучы агымдагы елның 1 июненнән дә соңга калмыйча, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе муниципаль органы (бүлеге) җитәкчесе һәм мәгариф оешмасы җитәкчесе белән килештерелгән гаризаны, әлеге Положениенең 2.6 пунктында күрсәтелгән документлар пакетын «Гомуми белем предметлары буенча Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабы призерларын һәм җиңүчеләрен әзерләгән педагогик хезмәткәрләргә ярдәм» грантының оештыру комитетына кәгазь һәм электрон мәгълүмат чыганакларында: 420036, Казан шәһәре, Социалистик урамы, 5 нче кат, 4 нче каб. 3 (9-00дән 17-00гә кадәр, төшке аш 12-00 дән 13-00гә кадәр; шимбә, якшәмбе-яллар) адресы буенча тапшырырга кирәк.

2.4. Грант алуга конкурс операторы-министрлыкның «Республика олимпиада үзәге» дәүләт автоном белем бирү учреждениесе (алга таба - «Республика олимпиада үзәге»ДАББУ).

2.5. Гариза агымдагы елның 1 июненнән соң бирелгән очракта, грантка дәгъва кылучы катнашу хокукыннан мәхрүм ителә.

2.6. Конкурста катнашу өчен, оешма җитәкчесе имзасы белән түбәндәге документларны тапшырырга кирәк:

конкурста катнашу нияте турында язма мөрәҗәгать булган гариза (1нче кушымта),

педагогик хезмәткәр педагогик эшчәнлек алып бара торган мәгариф оешмасының федераль законнар нигезендә бирелгән белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия күчермәсе;

Татарстан Республикасы белем бирү оешмаларының 9-11 нче сыйныф укучылары арасында гомуми белем фәннәре буенча Бөтенроссия олимпиадасының йомгаклау этабы җиңүчесе(ләре) һәм призер (лары) булуын раслаучы документлар.

## 3. Конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибе

3.1. Дәгъва кылучылар конкурсы тәкъдим ителгән документларга конкурсантның әлеге Положениенең 2.6 пункты таләпләренә туры килүенә экспертиза үткәрү юлы белән үткәрелә.

3.2. Конкурс материалларын бәяләү өчен комиссия рәисе һәм комиссия әгъзалары составында 13 кешедән дә ким булмаган санда Республика конкурс комиссиясе төзелә.

3.3. Республика конкурс комиссиясенең персональ составы Министрлык боерыгы белән раслана.

3.4. Республика конкурс комиссиясе әгъзалары Конкурста катнаша торган мәгариф оешмалары җитәкчеләре була алмый.

3.5. Республика конкурс комиссиясе утырышлары кирәк булган саен уздырыла һәм аларда составның яртысыннан артыгы катнашса, хокукый булып санала.

3.6. Республика конкурс комиссиясе:

агымдагы елның 20 июненә кадәр бирелгән гаризаларны карый;

агымдагы елның 25 июненә кадәр экспертиза нәтиҗәләре буенча эксперт бәяләмәләрен рәсмиләштерә (тапшырылган документларның 2 пункт таләпләренә туры килүен билгели.;

агымдагы елның 29 июненә кадәр конкурста катнашучыларның барысы өчен дә җыелган балларның гомуми (күптән азга) санын күрсәтеп, төзелгән исемлекне формалаштыра.

3.7. Дәгъва кылучыларның тәкъдим ителгән документларын карау нәтиҗәләре буенча Республика конкурс комиссиясе аларның әлеге Положениенең 2.6 пункты таләпләренә туры килү-килмәве турында Карар кабул итә.

3.8. Грант бирү турындагы карар Татарстан Республикасы белем бирү оешмаларының 9 - 11 нче сыйныф укучылары арасында гомуми белем фәннәре буенча Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабында җиңүче(ләр)не/ призер(лар)ны әзерләүдә катнашу нәтиҗәләре турында ,белә торып, дөрес булмаган, тулы яки ялган мәгълүматлар ачыкланганда. кабул ителми.

3.9. Конкурс нәтиҗәләре ТР мәгариф оешмаларының 9-11 сыйныфларында белем алучыларның гомуми белем бирү фәннәре буенча мәктәп укучыларының Бөтенроссия олимпиадасының йомгаклау этабында катнашуларының ирешелгән нәтиҗәләре нигезендә, нәкъ менә әзерләнгән призерлар/ җиңүчеләр саны белән билгеләнә

Конкурс нәтиҗәләре буенча Республика конкурс комиссиясе грант суммасын исәпкә алып күрсәтелгән грант алучылар исемлеген төзи:

Гомуми белем бирү фәне буенча Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабында 1 призер (10 000 сум х 12 ай) = 120 000 сум;

гомуми белем бирү фәне буенча Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабында 2 призер (15 000 сум х 12 ай) = 180 000 сум;

гомуми белем бирү фәне буенча Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабында 3 призер (20000 сум х 12 ай) = 240 000 сум;

гомуми белем бирү фәне буенча Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабында 4 призер (25 000 сум х 12 ай) = 300 000 сум;

Гомуми белем бирү фәне буенча Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабында 5 призер (30 000 сум х 12 ай) = 360 000 сум;

гомуми белем бирү фәне буенча Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабында 10 һәм аннан күбрәк призер (40 000 сум х 12 ай) = 480 000 сум;

гомуми белем бирү фәне буенча Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабында 1 җиңүче (15 000 сум х 12 ай) = 180 000 сум;

гомуми белем бирү фәне буенча Бөтенроссия олимпиадасының йомгаклау этабында 1 җиңүче + призер (25 000 сум х 12 ай) = 300 000 сум;

гомуми белем бирү фәне буенча Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабында 1 җиңүче + 2 призер (30 000 сум х 12 ай) = 360 000 сум.

гомуми белем бирү фәне буенча Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабында 1 абсолют җиңүче (20 000 сум х 12 ай) = 360 000 сум.

гомуми белем бирү фәне буенча Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабында 1 абсолют җиңүче + 1 җиңүче + 1 призер (45 000 сум х 12 ай) = 540 000 сум.

гомуми белем бирү фәне буенча Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабында 1 абсолют җиңүче + 2 җиңүче + 2 призер (65 000 сум х 12 ай) = 780 000 сум

3.10. Конкурс нәтиҗәләре белән риза булмаган очракта, конкурста катнашкан грантка дә кылучы Конкурс комиссиясенә апелляция бирергә хокуклы. Апелляция, дәгъва кылучылар конкурсы нәтиҗәләрен игълан иткәннән соң, эш көннәрендә исәпләнгән ун көнлек срокта Республика конкурс комиссиясе рәисе исеменә язма ирекле формада бирелә.

3.11. Республика конкурс комиссиясе апелляция бирү вакыты тәмамланганнан соң, бер эш көне эчендә, апелляцияне карый. Апелляция буенча Республика конкурс комисиясе карарлары ачык тавыш бирү юлы һәм катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

Тавышлар тигез булган очракта, республика конкурс комиссиясе рәисе хәлиткеч тавыш бирергә хокуклы. Апелляцияне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча республика конкурс комиссиясе түбәндәге карарларның берсен чыгара:

апелляцияне кире кагу һәм игълан ителгән нәтиҗәләрне саклау турында; апелляцияләрне канәгатьләндерү, дәгъва кылучыны грант алуга конкурсның икенче турына чыгару турында.

3.12. Апелляцияне карау Республика конкурс комиссиясе тарафыннан утырышта катнашучы республика конкурс комиссиясе рәисе һәм барлык әгъзалары кул куйган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

3.13. Республика конкурс комиссиясенең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

3.14. Сайлап алу материаллары, аларны раслау турында Карар кабул ителгән көннән соң, эш көннәрендә исәпләнгән 5 көн вакыт эчендә, Министрлыкның рәсми сайтында: программалар һәм проектлар / укытучыларга грантлар/ «Гомуми белем

бирү фәннәре буенча Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабы призерларын һәм җиңүчеләрен әзерләгән педагогик хезмәткәрләргә ярдәм» бүлекчәсендә урнаштырыла .

3.15. Грант алучылар исемлеге министрлык боерыгы белән раслана.

## 4.Бәйгене финанслау

Грант бирү максатларында субсидия бирү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

«Гомуми белем фәннәре буенча
Бөтенроссия мәктәп укучылары
олимпиадасының йомгаклау этабы
призерларын һәм җиңүчеләрен
әзерләгән педагогик хезмәткәрләргә ярдәм
гранты турындагы положениегә кушымта»

ЫШАНДЫРАМ
___________________________
муниципаль берәмлек исеме)
башкарма комитетның мәгариф
идарәсе (бүлеге) җитәкчесе
____________________(ФИО)
"____”____________201_ ел

РАСЛЫЙМ
___________________________
белем бтрү оешмасы исеме
җитәкчесе____________Ф.И.О
“_____2__________201_ел

Конкурста катнашу өчен
Гариза

| Гариза бирүче (дәгъва кылучы катнашучының исем-фамилиясе) | дәгъва кылучы педагогик эшчәнлек алып бара торган мәгариф оешмасы җитәкчесе (тулысынча) ФИО | Мәгариф оешмасының юридик адресы, телефон, электрон адресы | Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларының 9-11 сыйныф укучылары арасында гомуми белем фәннәе буенча мәктәп укучыларының Бөтенроссия олимпиадасының йомгаклау этабы җиңүчесе(ләре) һәм призер (лары) булуын раслаучы һәмирешелгән нәтиҗәләр һәм документлар исемлеге |
|---|---|---|---|
| | | | |

Битләр санын күрсәтелгән (Положениенең 2.6 пунктындагы документлар исемлеге ) кушымта.

Документлар белән гариза бирү тегелгән һәм номерлар куелга, мәгариф оешмасы җитәкчесе мөһере белән ныгытылган булырга тиеш.

Күрсәтелгән адрес буенча кәгазьдә мөһерләнгән конвертта тапшырыла.